| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МИЧУРИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МИЧУРИН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

06.06.2024 № 11

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 5 июнендәге 20 номерлы (2023 елның 1 августындагы №27 номерлы үзгәрешләр белән) «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 5 июнендәге 20 номерлы (2023 елның 1 августындагы №27 номерлы үзгәрешләр белән) «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 10, 11 һәм 12 пкнктчалар белән тулыландырырга:

«10) 2024 елның 01 гыйнварына варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затлардан бурычлар булу;

11) 2024 елның 01 гыйнварына 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

12) 2024 елның 01 гыйнварына Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән судка аны түләтү турында гариза бирү срогы тәмамланганнан соң физик затлардан җирле салымнар буенча 500 сумнан артмаган бурычлар булуы.»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 2 пункт белән тулыландырырга:

«2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып тора:

1) карарның 1 пунктының 10 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

- физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

- үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

- мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүматлар булмау турында салым органы белешмәсе;

2) карарның 1 пунктының 11 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

- оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) карарның 1 пунктының 12 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

- салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булу турында белешмәсе.»;

в) 2, 3, 4, 5 пунктларын 3, 4, 5, 6 пунктлары дип санарга.

2. Әлеге карарны торак пунктның Мичурин авылы түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин авылы, Совет урамы, 26 йорт административ бина, Совет урамы, 28 йорт-СДК, Яңа Сережкино авылы, Үзәк урамы, 9 йорт-СДК, Үзәк урамы, 15 йорт-мәктәп, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
Мичурин авыл җирлеге
берәмлеге башлыгы, Совет рәисе Р.Ә.Иванова

ИНН 1625000817
КПП 164901001